РАССМОТРЕНО
на заседании педагогического
совета МБОУ «Ирнурская НОШ»
Протокол №1 от 30.08.2023г.

УТВЕРЖДЕНО
Директор МБОУ «Ирнурская НОШ»
________________/Гайсина Н.Р./
Приказ №42-О/Д
от 30.08.2023 г.

РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

учебного курса «Родной
(татарский) язык»

начальное общее образование

1-4 классы

Составили: учителя начальных классов Ибраева М.В.
Гайсина Н.Р.

д. Ирнур, 2023г.

**Татар теленнән 1-4 сыйныфларда эш программасы**

Аңлатма язуы

Милли мәктәптә укыту-тәрбияләү процессын оештыру укытыла торган фәннәр системасына нигезләнгән.Аларны үзләштерүче укучылар хәзерге белем бирү нигезләренөйрәнәләр, шулай ук тиешле дәрәҗәдәге психик үсешкәия булалар.

Укытыла торган фәннең үзәге булып программа тора.Ә программа — үзләштерергә тиешле белем һәм куллана белү тасвирламасы. Аның буенча укыту сроклары һәм уку процессының башка моментлары билгеләнә. Программага карап билгеле бер типтагы фикерләү проектлаша. Ә фикерләү тибы тәкъдим ителгән уку материалын үзләштергәндә формалаша. Шуңа күрә программа төзү мәсьәләсе методик тәрбия системасында тамырдан һәм комплекслы программа итеп каралырга тиеш.

Татар теле курсының **бурычы** — аңлап һәм дөрес укырга, сөйләргә, грамоталы язарга һәм китап белән эшләргә өйрәтү.

Балаларны укырга-язарга өйрәтү уку елының I—IIIчирекләрендә тәмамлана. Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә карап, әлеге чорны 10—15 көнгә элегрәк тә төгәлләргә мөмкин. Бу вакыт эчендә балалар фонемаларны дөрес ишетергә, укырга, язарга һәм сөйләргә өйрәтелгән була. Ә инде иҗади үсеш технологиясендә эшләгәндә укучыларда уку эшчәнлеге дә бу чорга формалаша башлый, чөнки бала бу этапта инде эзләнүче позициясенә баскан була.

Беренче сыйныфтан ук балаларны дөрес язуның гомуми принцибын үзуку эшчәнлекләре нигезендә ачу дәрәҗәсенә җиткерү өчен, язарга өйрәтүдә авазлар системасын өйрәнүне салу урынлы. Дөрес язарга өйрәтү фонематик принципка корылган, шуңа күрә укыту процессында сүзне эзләү, атау Функциясен ачыклау һәм сөйләмнән сүзне аерып алу ысулын | кертү мөһим момент булып тора.

Сүзнең аваз формасын күрсәтү, аваз төзелешенең моделен бирү, иҗек төзү функциясен үзләштерү сүзне хәрефләр белән дөрес язу ысулын ачыклауга китерә. Монда инде орфограмма төшенчәсе кертелә.

Грамотага өйрәтү чорында ук [о], [ө], [э], [ү] авазларының хәрефләр белән тамгалану үзенчәлекләрен үзләштерәләр. [й] авазын хәрефләр белән билгеләү шартларын, ъ һәм ь хәрефләренең эшләрен күзәтәләр.

Традицион методикадан аермалы буларак, ь хәрефе иң элек я, ю хәрефләренең дөрес укылышын күрсәтүче буларак кертелә.

[к], [г], [н], [г] авазларыннан алда [ң] авазы килгән очраклар карала.

[в], [w], [h] авазларын өйрәнүдә зур эш башкарыла.

1 нче һәм 3 нче сыйныфның беренче яртыеллыгында фонетика тирәнтен өйрәтелә, катлауландырыла. Өченче сыйныфның икенче яртыеллыгында һәм дүртенче сыйныфта орфограммаларны кабатлау системалы рәвештә күнегүләргә кертелә. Күнегүләр фонетика, грамматика белән тыгыз бәйләнештә өйрәнелергә тиеш дигән принциптан чыгып төзелә. Грамматик формаларны өйрәнү, грамматиканы белү өчен генә булмыйча, ә шул формаларны сөйләмдә дөрес куллану, дөрес әйтү һәм дөрес язу максатларын берләштерүне күздә тота. Монда сүзләрнең дөрес язылышын үзләштерү сү:з төркемнәренең төрләнешенә, кушымчалар язылышының морфологик принципка нигезләнүенә бәйле.

Программада сүз лексик һәм грамматик планда карала, сүзлек эше аеруча зур урын алып тора. Һәр дәрестә 1-2 яңа сүз бирелә, 10 дәрес үткәннән соң ул сүзләрне үзләштерү дәрәҗәсен тикшерергә мөмкин. Сүзлек өстендә эш планлы һәм системалы үткәндә генә аның нәтиҗәсе күренә.

Грамоталы язуның тагын бер өлеше булып сүз төзелешен ныклы үзләштерү тора. Сүзләрнең тамырын һәм кушымчасын билгеләү ысулы «Сүз төркемнәре» кебек зур теманы аңлап үзләштерүгә нык булышачак.

4 нче сыйныфта өйрәнелгән материалны ныгыту һәм бәйләнешле сөйләм

телен үстерү дәресләренә зур урын бирелә.

Контроль диктант өчен нормалар

| Сыйныф | I яртыеллык | II яртыеллык |
|---|---|---|
| 1 | - | 15-17 сүз |
| 2 | 25-30 сүз | 35-40 сүз |
| 3 | 45-50 сүз | 55-60 сүз |
| 4 | 65-70 сүз | 75-80 сүз |

Изложениеләр өчен текстларның күләме һәр сыйныфта 15-20 сүзгә артыграк була.

Билгеле бер теманы үтеп бетергәннән соң, язма эшләр бер-бер артлы бирелә, чөнки укучылар үзләренең белемнәрен тикшерхгә һәм яңа шартка күчерергә психологик яктан әзер булалар.

**Родной (татарский) язык ,1класс,Обучение письму -22 урока.**
**Р.Р.Шамсетдинова, И.Х.Мияссарова, Ф.Ш.Гарифуллина**

| № | Тема | Тема | Укыту эшчәнлегенең төрләре | Материал үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре | Үткәрү вакыты<br>План буенча | фактически |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Җөмлә. | Предложение | Җөмлә турында төшенчә бирү. График схемалар ярдәмендә сөйләмне җөмләләргә, җөмләне сүзләргә аеру. | Сузык авазларның билгеләрен, җөмләне сүздән аера белергә,кисмә хәрефләр белән эшләү күнекмәләре булдырырга. | | |
| 2 | А, а хәрефләре. | Буквы А,а<br>. | А, а хәрефләре белән таныштыру.<br>(А) – калын сузык булуын төшендерү. | А, а хәрефләрен яза белергә тиешләр. | | |
| 3 | Ә,ә хәрефләре. | Буквы Ә,ә. | Ә, ә хәрефләре белән танышу. (А) – калын сузык, (Ә) – нечкә сузык булуын төшендерү. | Ә, ә хәрефләрен яза белергә тиешләр. | | |
| 4 | Ы , ы хәрефләре һәм<br>Э, э хәрефләре. | Буквы Ы ,ы и буквы Э,э. | Ы,ы хәрефләре белән таныштыру.<br>Э,э хәрефләре белән таныштыру.<br>Сүзләргә иҗек – аваз анализы ясау. | Ы, ы хәрефләрен,<br>Э, э хәрефләрен яза белергә,<br>Э хәрефенең сүзнең башында язылуын белергә тиешләр. | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Схемалар белән сүзләр төзү.“Калын сузык, нечкә сузык “уены. | | | |
| 5 | И,и хәрефләре. | Буквы И,и . | И,и хәрефләре белән таныштыру. | И, и хәрефләрен яза белергә тиешләр. | | |
| 6 | Ү,ү һәм У,у хәрефләре. | Буквы Ү,ү и буквы У,у. | Ү,ү хәрефләре белән таныштыру.<br>У,у хәрефләре белән таныштыру. | Ү, ү һәм У,у хәрефләрен яза белергә тиешләр. | | |
| 7 | О ,о һәм Ө, ө хәрефләре. | Буквы О, о и буквы Ө, ө .<br>Правила( о)-о,ы.<br>(ө) –ө,е | О,о һәм Ө,ө хәрефләре белән таныштыру, о хәрефе белән чагыштыру.<br>О, Ө хәрефләренең сүз башында яки сүзнең беренче иҗегендә генә булуын күзәтү.“Очты, очты..”уены | О ,о һәм Ө, ө хәрефләрен яза белергә тиешләр.<br>О хәрефенең сүз башында яки сүзнең беренче иҗегендә генә язылуын белергә тиеш<br>Болыт (болот) борыч (бороч)<br>колын (колон).<br>Ө хәрефле сүзләрне дөрес әйтә белергә, ө хәрефенең сүзнең беренче иҗегендә генә язылуын белергә тиешләр.<br>өрек (өрөк) төлке(төлкө) | | |
| 8 | Н,н хәрефләре һәм Л,л хәрефләре | Буквы Н,н и буквы Л,л | Н, н хәрефләре белән таныштыру.<br>Л,л хәрефләре белән таныштыру. Сүзләрне язу. | Н,н, Л,л хәрефле сүзләрне дөрес итеп яза белергә тиешләр. | | |
| 9 | М, м хәрефләре һәм Р,р хәрефләре | Буквы М, м и буквы Р,р | М,м һәм Р,р хәрефләре белән таныштыру.<br>“Кем күбрәк сүз төзи?” уены. | М, м хәрефләре һәм Р, р хәрефләре булган сүзләрне дөрес яза белергә тиешләр. | | |
| 10 | Й, й һәм ң | Буквы Й, й и | Й, й һәм ң хәрефләре белән | Й,й, ң хәрефләре белән сүзләр, | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | хәрефләре. | буква ң. | таныштыру. | җөмләләрне дөрес итеп яза белергә тиешләр. | | |
| 11 | Я, я хәрефләре һәм Ю,ю хәрефләре | Буквы Я, я и буквы Ю,ю | Я,я һәм Ю,ю хәрефләре белән таныштыру. | Я, я хәрефләре һәм Ю,ю хәрефләре белән сүзләр, җөмләләрне дөрес итеп яза белергә тиешләр.<br>Яр (йар) оя (ойа) лилия (лилийә) | | |
| 12 | Е, е хәрефләре. | Буквы Е, е . | Е,е хәрефләре белән таныштыру. | Е, е хәрефләре белән сүзләр, җөмләләрне дөрес итеп яза белергә тиешләр.<br>Калын сузыклы сүзләрдә е хәрефенең “йы” булып укылуын белергә ,сүзләрне дөрес яза белергә тиешләр.<br>Нечкә сузыклы сүзләрдә е хәрефенең “йэ” булып укылуын белергә ,сүзләрне дөрес яза белергә тиешләр. | | |
| 13 | Д, д һәм Т, т хәрефләре. | Буквы Д, д и буквы Т, т. | Д, д һәм Т, т хәрефләре белән таныштыру. | Д, д һәм Т, т хәрефләре белән сүзләр, җөмләләрне дөрес итеп яза белергә тиешләр. | | |
| 14 | З, з һәм С,с хәрефләре. | Буквы З, з и буквы С,с. | З, з һәм С,с хәрефләре белән таныштыру. Калын сузыклы, нечкә сузыклы кушылмаларны язу. | З, з һәм С, с хәрефләре белән сүзләр, җөмләләрне дөрес итеп яза белергә тиешләр. | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 15 | Г,г һәм К,к хәрефләре. | Буквы Г, г и буквы К,к. | Г, г һәм К, к хәрефләре белән таныштыру. Калын сузыклы, нечкә сузыклы кушылмаларны язу. | Г,г һәм К,к хәрефләре булган сүзләрне дөрес итеп яза белергә тиешләр. | | |
| 16 | В, в һәм Ф, ф хәрефләре. | Буквы В, в и буквы Ф,ф | В, в һәм Ф, ф хәрефләре белән таныштыру. | В, в һәм Ф, ф хәрефләре булган сүзләрне дөрес итеп яза белергә тиешләр. Сүзләрне яңгырашы яки мәгънәсе ягыннан чагыштыра белергә тиешләр Сафа-Вафа. | | |
| 17 | Б, б хәрефләре һәм П ,п хәрефләре. | Буквы Б, б и буквы П,п. | Кушылмалар укыту. | Б, б һәм П ,п хәрефләре булган сүзләрне дөрес итеп яза белергә тиешләр. | | |
| 18 | Ж, ж һәм Ш , ш хәрефләре. | Буквы Ж, ж и буквы Ш,ш. | Схема буенча уку. | Ж, ж һәм Ш , ш хәрефләре булган сүзләрне дөрес итеп яза белергә тиешләр. | | |
| 19 | Җ, җ һәм Ч ,ч хәрефләре. | Буквы Җ, җ и буквы Ч, ч. | Җ,җ һәм Ч,ч хәрефләре белән таныштыру.<br>Ж,ж хәрефләре белән чагыштыру.<br>Кушылмалар, сүзләр язу. | Җ, җ һәм Ч ,ч хәрефләре булган сүзләрне дөрес итеп яза белергә тиешләр. | | |
| 20 | Х, х һәм Һ, һ хәрефләре | Буквы Х,х и буквы Һ, һ . | Х, х һәм Һ, һ хәрефләре белән таныштыру. | Х, х һәм Һ, һ хәрефләре булган сүзләрне дөрес итеп яза белергә тиешләр. | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 21 | Щ, щ һәм Ц,ц хәрефләре | Буквы Щ ,щ и буквы Ц,ц . | Щ, щ һәм Ц,ц хәрефләре белән таныштыру. | Щ, щ һәм Ц,ц хәрефләре булган сүзләрне дөрес итеп яза белергә тиешләр. | | |
| 22 | Ь һәм Ъ хәрефләре | Буква Ь и букваЪ . | Ь ,ъ хәрефе белән таныштыру, ь, ъ билгесенең иҗек яки сүз ахырында булганлыгын күзәтү | ь , ъ хәрефләренең аваз белдермәгәнен,дөрес итеп яза белергә тиешләр. | | |

**Родной (татарский) язык 1 класс.**
**З.И.Замалетдинова, 11уроков**

**Төп бурыч - укучыларны хатасыз язарга өйрәтү.**

| № | Тема | Тема | Укытучы эшчәнлеге | Укучылар эшчәнлеге | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | план | факт |
| **1** | Сүзләр. | Слова. | Сүзнең мәгънәсе һәм аның нәрсәләрдән төзелгәнлеге турында күзаллау формалаштыру. | Сүзнең лексик мәгънәсен ачыклау.<br>Җөмлә төзү күнекмәсен үзләштерү. | | |
| 2 | Авазлар һәм хәрефләр. | Звуки и буквы. | Сүзнең авазлардан төзелгәнлеге һәм авазларның хәрефләр белән тамгаланышы күнекмәсен булдыру. | Хәрефнең аваз тамгасы икәнен үзләштерү. | | |
| 3 | О хәрефе. | Буква О. | О хәрефенең сүз башында яки сүзнең беренче иҗегендә генә язылу күнекмәсен булдыру. | О хәрефен татар сүзләрендә дөрес куллану күнекмәсен үзләштерү. | | |
| 4 | Ө, Е, Э хәрефләре. | Буквы Ө, Е, Э. | Ө, Е, Э хәрефләре кергән сүзләрнең дөрес язылышы күнекмәсен булдыру. | Ө, Е, Э хәрефләре кергән сүзләрнең дөрес язылышын үзләштерү. | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 5 | Сүзнең иҗекләргә бүленеше. | Деление слов на слоги. | Сузыклар санына карап иҗек санын дөрес билгеләү күнекмәсен формалаштыру. | Сүзнең иҗекләргә бүленешен үзләштерү. | | |
| 6 | Калын һәм нечкә сузыклар. | Твёрдые и мягкие гласные. | Татар телендә сүзнең калын яки нечкә әйтелүе алардагы сузык авазларга бәйле икәнен аңлату. | Сүзнең калын яки нечкә әйтелешен үзләштерү. | | |
| 7 | Яңгырау һәм саңгырау тартыклар. Парлы һәм парсыз тартыклар. | Звонкие и глухие согласные. | Яңгырау һәм саңгырау парларын аера белү күнекмәсен формалаштыру. Парсыз тартыклар турында белешмә бирү. | Яңгырау һәм саңгырау парларын аера белүне үзләштерү. | | |
| 8 | Алфавит. Сүзләрне алфавит тәртибендә язу. | Алфавит. Использование алфавита. | Алфавитны хәтерләү күнекмәсен үстерү. | Алфавитны яттан үзләштерү . | | |
| 9 | Предмет, эш-хәрәкәт,билге белдергән сүзләр. | Слова, которые обозначают предмет, действие предмета, признак предмета. | Предмет, эш-хәрәкәт,билге белдергән сүзләрне сорау куеп тану ысулын формалаштыру. | Предмет, эш-хәрәкәт,билге белдергән сүзләрне тану күнекмәсен үзләштерү. | | |
| 10 | Баш хәрефтән язылa торган сүзләр. | Заглавная буква в словах. | Баш хәрефтән языла торган сүзләрне аерып тану күнекмәсен формалаштыру. | Баш хәрефтән языла торган сүзләрне тану күнекмәсен үзләштерү. | | |
| 11 | Грамматик биремле диктант. | Диктант с грамматическим заданием . | Үзләштергәннәрне тикшерү. | Ишетә һәм яза белү күнекмәсен формалаштыру. | | |

## Аңлатма язуы

<u>2 нче сыйныф өчен татар теле фәненнән эш программасы:</u>

**Татар теле дәресенең максаты**

-укучыларда уңышлы аралашу сәләте булдыру-әйтмә һәм язма сөйләмне үстерү, кара-каршы сөйләшү осталыгы, монолог төзү һәм шулай ук гомуми кулҗтура күрсәткече булган грамоталы язу күнекмәләре булдыру, укучыларны тел фәненең төп мәгълуматлары белән таныштыру һәм шулар нигезендә аларның тамга символик һәм логик фикерләвен үстерү, татар теленең башка телләр белән берлектә дөньяның фәнни картинасын тудыруда катнашуы,аның милләте саклап калуда, халыкның, шәхеснең үзенчәлеген югалтмауда ышанычлы нигез, җәмгыятнең яшәешенә зарури шарт булуы турында күзаллау барлыкка китерү.

**Бурычлар**

-балаларның сөйләм осталыгын, фикерләү сәләтен һәм иҗади хыялын үстерү, ана телендә аралашу максатына, бурычларына,шартларына туры килгән тел чаралары сайлый белергә, уй-фикерләрен төгәл белдерергә һәм әңгәмәдәше әйткәнне тәңгәл аңларга күнектерү

-телнең лексикасы,фонетикасы һәм грамматикасы буенча программада күрсәтелгән башлангыч белемнәрне үзләштерүгә ирешү

-укучыларда дөрес уку һәм язу күнекмәләре булдыру, диалогта катнашырга һәм аларны зур, катлаулы булмаган монолог тибында төзеп әйтергә, тасфирлама, хикәяләү, фикер йөртү төрендәге кечкенә текстлар төзергә өйрәтү, уңышлы аралашу сәләте тәрбияләү.

**Курс 34 сәгатькә исәпләнгән , атнага – 1 сәг.**
**Контроль эшләр саны :**
Конторoль диктант - 4
Контроль күчереп язу- 2

## Эчтәлекнең структурасы

Башлангыч сыйныфларда ана телен өйрәнү –балаларга тел белеме буенча системалы мәгълүматләр бирү һәм сөйләм үсешен тәэмин итүдә беренчел этап.Бу чорда ана телен өйрәнү башка фәннәр белән тыгыз бәйләнештә алып барыла.Татар теле дәресләрендә телнең системасы тирәнтен өйрәнелә,сөйләм культурасы үзләштерелә. Кече яшьтәге балаларның аралашу гамәлендә актуаль булган ситуацияләрдә кирәкле осталык һәм күнекмәләр булдырыла, сөйләм җанрының төрләре (записка,хат,котлау, чакыру язу) үзләштерелә.Орфография һәм пунктуацион кагыйдәләре фонетика,морфология, морфемика һәм синтаксисны өйрәнү кысаларында үзләштерелә.Ана теленең орфография принциплары белән танышу да кертелә.

Дәреслекне төзүче автор (З. И. Җамалетдинов) тәкъдим итә торган УМК (программа , бер кисәктән торган дәреслек, методик кулланма, мөстәкыйль эш дәфтәре), ана телен укытуның традицион формаларын читкә какмыйча, укучыларда тел берәмлекләренә, заман таләпләреннән чыгып, уңай мөнәсәбәт тәрбияләүгә юнәлтелә.Дәреслекне төзүче автор 2 сыйныф укучысының яшь үзенчәлегенә нигезләнеп эшләгәннәр.Дәреслекләрдә “яшәүче” геройлар укучыларга программа материалын үзләштерергә ярдәм итәләр. Татар теле дәресләрендә укучыларның сүз байлыгын арттыру, даими рәвештә орфоэпик һәм орфографик нормаларны төгәл үтәү максатыннан,”Дөрес әйт””Дөрес яз” сүзлекләре һәм “Аңлатмалы сүзлек” белән эшләүгә нык игътибар ителә.Дәреслектән укучылар яңа сүзләр белән танышалар,ә икенчесендә әлеге сүзләр белән сүзлекләр ярдәмендә эшләп, аларның дөрес әйтелеше һәм язылышы ныгытыла.”Аңлатмалы сүзлек”тән яңа өйрәнгән сүзнең мәгънәсен ачыклыйлар.Шул сүзләр белән сүзтезмә һәм җөмләләр төзетү, аларны диалог һәм монологлар төзүдә файдалану укучыларның сүз байлыгын арттырачак, бәйләнешле сөйләм оештырырга ярдәм итәчәк.Сөйләм телен үстерү, сүз байлыгын арттыру төрле язма эшләр үтәгән вакытта да алып барыла.Сүзлек, искәртмәле, сайланма,күрмә, хәтер, иҗади,ирекле,аңлатмалы диктантлар,зур булмаган текстны күчереп язу кебек эшләрдә дә андый күнекмәләр булдырырга ярдәм итә.(Диктант өчен үрнәк текстлар дәрес планында бирелә.Текстлар (язма эшләр) укучыларның яшь үзенчәлекләренә туры китереп, телне белү дәрәҗәсен истә тотып сайлана)

## Белем бирүнең төп юнәлешләре

“Татар теле” фәненең материалы түбәндәге юнәлешләрдә бирелә

-телнең системасы (лингвистика фәненең нигезләре), сөйләм, лексика, фонетика,графика, сүз составы(морфемика),грамматика(морфология һәм синтаксис), орфография, сөйләм үстерү.

## Уку эшчәнлегенең универсаль гамәлләре

Татар телен укытуда укучыларга танып белүгә этәргеч бирү, уку эшчәнлегендә мөстәкыйльлек, иҗатка омтылыш тәрбияләү, хезмәттәшлекне оештыра,эшне планлаштыра,уку хезмәтендә максат кабул итү,аңа ирешү өчен этапара бурычлар кую һәм аларга ирешү өстендә эшләү осталыгы булдыру зур әһәмияткә ия.”Татар теле” фәнен өйрәнгәндә, укуда кирәкле акыл эшчәнлегенең гомуми алымнары формалаша чагыштыру, гомумиләштерү, классификацияләү,абстрактлаштыру.Эшне башка зат тикшерүеннән үзең тикшерүгә, нәтиҗәле генә түгел,эш алымнары бәяләүгә бик кирәкле регулятив гамәлләр.Дәресләрдә сүзнең аваз схемасын куллану, җөмлә кисәкләренең астына сызу,сүзнең мәгънә кисәкләрен билгеләү һәм башка шундый эшләр тамга-символик уку гамәлләре булдырырга ярдәм итү.модельләштерү-тойгы объектның билгеләрен графика яки тамга-символик формага күчерү, шул модельне өйрәнелә торган фәннең гомуми законнарына буйсындырып үзгәртү,өйрәнгән теманы схема, сызым,план формасында күрсәтү Мондый универсаль эш гамәлләренә ия булу башка фәннәрне өйрәнүгә ныклы нигез

**Курсның эчтәлеге**

**<u>Фонетика һәм орфоэпия</u>**

Беренче сыйныфта алган белемнәрне, эш осталыгын һә күнекмәләрне ныгытып,тирәнәйтеп, гомумиләштереп, системалаштырып,лингвистик компетенция булдыруга нигез салу.Сузык һәм тартык авазларны дөрес аерып, сүзне ижекләргә бүлеп,андагы авазларны ачык әйтеп, хәрефләрне дөрес атап, сүздә аваз-хәрефләрнең санын һәм эзлеклелеген билгеләү.

Калын һәм нечкә сузык авазларның икенче функциясен – сүзнең калын һәм нечкә әйтелешен билгеләү –гамәли үзләштерү Е,я,ю хәрефләренең сүз башында һәм сузык авазлардан соң ике аваз белдергән очракларын танып белү һәм шул хәрефләр кергән сүзләрне дөрес уку, күчереп язу

Ъ ь хәрефләренең аваз белдермәгәнлеген истә тоту, шул хәрефләр кергән сүзләрне дөрес уку.

Баш һәм юл хәрефләрен дөрес куллануга күнегү һәм биремнәрне аңлап башкару.

Авазларның, сүз басымының мәгънә аеруда катнашуы, дәресләрдә өйрәнгән сүзләрне тиешле басым белән әйтү.

**<u>Графика</u>**

Татар алфавитын төгәл, хәреф исемнәрен дөрес итеп яттан белү.Төрле сүзлек һәм белешмәлекләр белән эшләгәндә, алфавиттан файдалану.Беренче хәрефенә карап, сүзләрне алфавит тәртибендә урнаштыру.

## **Сүз**

Сүзнең предмет (кем? нәрсә?), хәрәкәт(нишли?) һәм билге (нинди?)атамасы булуы.Сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне аера белү.Сүзтезмә һәм җөмләләрнең сүзләрдән төзелүе.Һәр җөмләнең нинди дә булса максат белән әйтелгәненә гамәли күзәтүләр.Тамыр сүзләр.Татар телендә сүз тамырның сүз башында булуын, үзгәрмәвен, кушымчаларның тамыр сүзгә сингармонизм законына бәйле рәвештә ялганып килүен күзәтү.(җир ,җирле, җирлеләр, җирсезлек,)

Кеше исемнәрен, фамилияләрен, шәһәр, авыл ,елга, исемнәрен, хайван кушаматларын баш хәреф белән язу.

## **Җөмлә**

Сөйләмне җөмләләргә аеру.Терминын кулланмыйча, җөмләнең нинди максат белән әйтелүенә күзәтүләр, шул максаттан чыгып, аңа дөрес интонациягә сайлау, хикәя, сорау җөмләләрнең азагында интонациягә бәйле рәвештә тыныш билгеләре куя белү

Җөмлә төзү алгоритмын гамәли үзләштерү

1.Җөмләнең үзәге итеп,нинди дә булса эш, шөгылж, хезмәт, эшчәнлек, хәл, хәрәкәт, хәбәр сайлау.

2.Моны кем башкара ала?

3.Бу эш, хәл, хезмәт, хәрәкәт кайда, кайчан, ничек булырга мөмкин?

Җөмлне төзүче баш кисәкләр . Ия һәм хәбәр.Аларны җөмләдә табу схемалар, сызыклар белән күрсәтү.Сораулар ярдәмендә җөмләдә сүзләр бәйләнешен билгеләү. Дәрестә укып тикшергән җөмләләрне ишетеп язу.

## **Бәйләнешле сөйләм**

Бәйләнешле сөйләмдә җөмләләрне узара бәйләнеше.Бер темага берләштерелмәгән аерым җөмләләрне текст белән чагыштыру.Текстның темасын билгеләү.Текстны кисәкләргә бүлү, шул кисәкләрдән берләштерү чараларын текстлар эчендә күзәтү.Зур булмаган текстларга исем кую.Укыган әсәрнең эчтәлеген сөйләү.Сюжетлы рәсемнәр буенча хикәя язу.Җөмләләрне тиешле тәртиптә урнашттырылмаган кечкенә текстларны тикшерү һәм төзәтеп язып кую.Шигырь, мәкаль,әйтем табышмаклар ятлау.

Язма эшләр: сүзлек диктанты, искәртмәле диктант,сайланма диктант, күрмә диктант,хәтер диктанты,иҗади диктант,аңлатмалы диктант,иректе диктант, контроль диктант

**2 нче сыйныф укучыларының белем дәрәҗәләрендә булачак нәтиҗәләр**

-сүзләрне,җөмләләрне, 30-40 сүзле текстны, хәрефләрен бозмыйча, төшереп калдырмыйча, хәреф өстәмичә, урыннарын алыштырмыйча, аңлаешлы, пөхтә итеп, каллиграфик дөрес язу

-сузык һәм тартык авазларны, калын һәм нечкә сузыкларны икеләнүсез аеру, анализ ясау, бирелгән теориягә таянып, аларга анализ ясау,бирелгән аваз схемасына,характеристика тиешле авазлар, сүзләр сайлау.

-сүзләрне иҗекләргә бүлү һәи иҗекләп юлдан-юлга күчерү, бә-рәң-ге, бәрәң-ге, бә-рәңге

- Кеше исемнәрен, фамилияләрен, шәһәр, авыл ,елга, исемнәрен, хайван кушаматларын баш хәреф белән язу.

-е,в,г,й,к,н,ң,о,ө,х,һ,э,ю,я хәрефләре, ый, йо,йө кушымчалары булган сүзләрне дөрес язу

-янәшә килгән бертөрле ике тартык аваз хәрефләре булган әллә, кәккүк.Габбас кебек сүзләрне, нечкә(калын) аеру билгесе кергән гади, программада булган сүзләрне (дөнья, ашъяулык) дөрес язу һәм юлдан –юлга күчерү

-сүзгә фонетик анализ ясау, иҗекләргә бүлү,авазларны сүздәге тәртиптә ачык, дөрес әйтеп атап чыгу,

-үзең язганны бирелгән үрнәк белән чагыштыру

-сүзләргә дөрес сорау кую һәм шуның нигезендә предметны ,предметның эшен,хәрәкәтен, билгесен, өстәмә предметны ,ярдәмче сүзләрне таба белү

-җөмләнең баш кисәкләрен таба бел-уку,уеннар, көндәлек тормыш, җәнлекләр, кош-кортлар турындагы темаларга 4-5 җөмләдән торган бәйләнешле текст төзеп сөйләү һәм язу

сүзләрнең әйтелешен, кулланышын, язылышын истә калдыру: *аваз,авыз, елга, бәрәңге, бияләй, борын, вакыт,гомер, гыйнвар, дөрес, дүшәмҗе, җавап, җомга,җөмлә,җылы,йөрәк,караңгы,көньяк,кыңгырау,маңгай,Мәскәү,муен,онык,оя,пәнҗешәмбе,савыт, сәгать,, сәлам, сеңел, тавык,тавыш, тәмле, төньяк, уен, уңыш,хайван,хөрмәт,һава,һаман,чаңгы,чәршәмбе,чия,шәһәр,шуа,эссе,юан,якшәмбе.*

***Укыту – методик кулланма***

1.Татар теле 2 сыйныф З. И, Җамалетдинова Казан. Татарстан китап нәшрияты, 2013 ел .

2. Татар теленнән Россия Федерациясе төбәкләрендә яшәүче татар укучылары өчен программалар. 1-4 нче сыйныфлар Казан Татар. китап. нәшрияты, 2014ел.

3. Диктантлар җыентыгы

**Укыту – тематик планлаштыру**

| № п/п | Дәреснең темасы | Тема урока | Дәреснең кыскача эчтәлеге | Укучыларның белем күнекмәләренә таләпләр | Өстәмә (мәҗбүри булмаган) белем | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | **кален** | **факт** |
| 1. | Авазлар һәм хәрефләр | Звуки и буквы.<br>Гласные звуки. | Сузык һәм тартык авазлар, аларның хәрефләре. Схемаларга карап сүзне табу | **Белергә тиеш:**<br>Аваз һәм хәреф аермасы.<br>**Башкара алырга тиеш:** | Бирелгән аваз схемасына сүзләр сайлау | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | -сүздән авазны аерып алу, аңа характеристика бирү;<br><br>-сүзгә аваз-хәреф схемасын төзү | | | |
| 2. | Яңгырау һәм саңгырау тартык авазлар. | Звонкие и глухие согласные звуки. | Яңгырау һәм саңгырау тартык авазлар таблицасын күзәтү, тартык авазлар һәм аларны язуда белдерә торган хәрефләр | **Белергә тиеш:** яңгырау һәм саңгырау тартык авазларны.<br><br>**Башкара алырга тиеш:**<br><br>Тартык авазлар булган сүзләрне дөрес язу һәм уку. | ”Дөрес әйт” һәм “Дөрес яз” сүзлекләре белән эш. | | |
| 3. | Иҗек. Сүзләрне юлдан – юлга күчерү. | Слог.Перенос слов. | Сүзләр бер юлдан икенче юлга иҗекләп күчерелә, сузык аваз иҗек төзи. | **Белергә тиеш:** --Сузык аваз иҗек төзи;<br><br>-һәр иҗектә сузык аваз бер генә була;<br><br>- иң кечкенә иҗек бер сузыктан тора;<br><br>-сүзнең бер хәрефен иҗек булса да, юл ахырында калдырырга да, яңа юлга күчерергә дәярамый;<br><br>- тавышсыз хәрефләр (ъ,ь) үзләреннән алдагы хәрефләреннән аерып күчерелмиләр<br><br>**Башкара алырга тиеш:** | сузык авазларны билгеләү | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | -Сүзләрне иҗекләргә бүлү, һәм иҗекләп, юлдан юлга күчерүнең катгый булмавын, аларның вариантларын белү**Белергә тиеш:**<br>сүзләрне иҗекләргә дөрес бүлү | | | |
| 4. | **Контроль диктант (№1)**<br>“Авазлар һәм хәрефләр” | Контрольный диктант “Звуки и буквы” | Укучыларның алган белемнәрен тикшерү. | **Башкара алырга тиеш:**<br>Сүз һәм җөмләләрне аңлап язу | | | |
| 5. | Сүздә аваз – хәреф саны. Калын һәм нечкә сузыклар | Звуко-буквенный разбор слов.Твёрдые и мягкие гласные. | | **Белергә тиеш** :сүздә аваз – хәреф санын билгеләү | | | |
| 6. | Е, ю,я хәрефләренең ике авазны белдергән очраклары | Буквы е,ю,я в словах. | Е,ю,я хәрефе сүз, иҗек башында килгәндә һәм сузык аваз хәрефләрен-нән соң [йы] [йэ ], аваз кушылмаларын белдерә<br>Тартыклардан соң | **Белергә тиеш:**<br>-сүз,иҗек башында, сузык аваз хәрефләреннән соң килгән е хәрефенең дөрес укылышын язылышын;<br>- тартыклардан соң килгән е хәрефенең дөрес язылышын, | Аңлатмалы сүзлек белән эш. | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | килгән е хәрефе [э] дип укыла. | укылышын;<br>-е хәрефенең [йы], [йэ ], [э] булып укылуын | | | |
| 7 | Ь һәм Ъ хәрефләре (нечкәлек һәм калынлык аеру билгесе) | Буквы ь и ъ. | Нечкәлек билгесенең ь, калынлык билгесенең язылышы..Гарәп теленнән кергән сүзләрдә нечкәлек билгесенең вазифасы.<br>Нечкә иҗек ахырында я, ю, е хәрефләре алдыннан килгән нечкәлек билгесенең вазифасы | **Белергә тиеш:**<br>- нечкәлек билгесе (ь) иҗекнең нечкә әйтелешен күрсәтү өчен языла;<br>- гарәп теленнән кергән сүзләрдә нечкәлек билгесе ь иҗекнең нечкә әйтелешен күрсәтү өчен языла<br>**Башкара алырга тиеш:**<br>-Өйрәнгән сүзләрдә нечкә тартыкларны сузык аваз хәрефләре яки ь билгесе белән күрсәтү;<br>-гарәп теленнән кергән сүзләрне дөрес язу | Җавабында нечкәлек билгесе (ь) булган табышмаклар язып алу. | | |
| 8 | Авазларның һәм сүз басымының мәгънә аеруда катнашуы. Баш һәм юл | Ударение.<br>Употребление заглавной<br>(прописной) буквы. | Авазлар һәм басым сүзләрнең мәгънәсен төгәл билгеләргә ярдәм итә.<br>Баш хәреф шәһәр,елга,урам,кеше исемнәре, | авазлар һәм басым сүзләрнең мәгънәсен төгәл билгеләргә ярдәм итә.<br>Баш хәреф шәһәр,елга,урам,кеше исемнәре, фамилияләре, хайван кушаматларын язганда кулланыла. | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хәрефләрен дәрес куллану. | | фамилияләре, хайван кушаматларын язганда кулланыла. | | | | |
| 9 | **Контроль диктант (№2)** “Сүзләр” | Контрольный диктант ”Слова” | Укучыларның алган белемнәрен тикшерү | **Башкара алырга тиеш:** Сүз һәм җөмләләрне аңлап язу | | | |
| 10 | Алфавит. | Алфавит. | Алган белемнәрне, эш осталыгын һәм күнекмәләрне ныгыту, тирәнәйтү, гомимумиләштерү, системалаштыру | **Башкара алырга тиеш:** -Татар алфавитын төгәл, хәреф исемнәрен дөрес әйтеп, яттан белү, сүзләрне алфавит тәртибендә урнаштыру | “Дөрес яз”, “Аңлатмалы сүзлек” һәм “Дөрес әйт” сүзлекләре белән эш | | |
| 11 | Алфавитны кулану . | Использование алфавита. | Алган белемнәрне, эш осталыгын һәм күнекмәләрне ныгыту, тирәнәйтү, гомимумиләштерү, системалаштыру | **Башкара алырга тиеш:** -Татар алфавитын төгәл, хәреф исемнәрен дөрес әйтеп, яттан белү, сүзләрне алфавит тәртибендә урнаштыру -Орфограммалы сүзләрне дөрес яза белү, биремнәрне төгәл үтәү | “Дөрес яз”, “Аңлатмалы сүзлек” һәм “Дөрес әйт” сүзлекләре белән эш | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 12 | Сүз .<br><br>Сүз – предмет, хәрәкәт, билге атамалары. | Слово.<br><br>Слова,<br><br>которые обозначают предмет, признак, действие. | Җөмләләр сүзләрдән төзелә; сүзләр авазлардан төзелә. Җөмлә тәмамланган уйны белдерә. Сүзләр предметны, предметның билгесен ,предметның эш – хәрәкәтен белдерәләр. | **Белергә тиеш:**<br><br>-сүз һәм җөмләнең аермасын<br><br>**Башкара алырга тиеш:**<br><br>-сүз, сүзттезмә, җөмләләрне аера белү;<br><br>-сүзтезмәләр төзеп яза белү | “Дөрес яз” сүзлеге белән эшләү, рәсем буенча сүзләр һәм җөмләләр төзү | | | |
| 13 | Сүзнең атау функциясен сораулар ярдәмендә билгеләү. | Слова,<br><br>которые обозначают предмет, признак, действие | Сүзнең атау функциясен сорулар ярдәмендә ачыклау | Сүзнең атау функциясен сорулар ярдәмендә ачыклау | | | | |
| 14 | Сүз һәм сүзтезмә. | Слова и словосочета-ния. | Сүзтезмә охшаш предметларны , эш яки хәлләрне бер – берсенән аерып күрсәтә. Сүзтезмәдә сүзләр узара бәйләнеп килә. | **Белергә тиеш:** Сүзтезмә охшаш предметларны , эш яки хәлләрне бер – берсенән аерып күрсәтә. Сүзтезмәдә сүзләр узара бәйләнеп килә. | | | | |
| 15 | **Контроль күчереп язу (№1)** | Контрольное списывание. | Игътибар белән дөрес күчереп язу. | **Башкара алырга тиеш:**<br><br>-өйрәнелгән кагыйдәләрне куллана | | | | |

| | | | | | | | |
